**Яр Чаллы шәһәре территориясендә җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән яшеренү урыннарында һәм башка биналарында халыкны саклау чаралары буенча**
**БЕЛЕШМӘЛЕК**

**1. Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналары турында гомуми төшенчәләр.**

**Яр Чаллы шәһәре җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналары халыкны** гадәти җимерү чараларының фугас һәм кыйпылчык тәэсиреннән, төзелеш конструкцияләре җимерекләре белән зарарланудан, шулай ук төрле катлы биналарның югарыда урнашкан катлары конструкцияләренең җимерелүеннән **саклау өчен билгеләнгән.**

**Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналары дип җирнең планлаштыру билгесеннән түбәнрәк, идәне булган биналарны аңларга кирәк.**

**Алар арасында:**

- биналарның подваллары һәм цоколь катлары, шул исәптән шәхси торак секторы;

- гаражлар, складлар һәм биналарның һәм корылмаларның аерым торган һәм подвал катларында, шул исәптән сәүдә һәм күңел ачу үзәкләрендә урнашкан башка биналар;

- иң гади яшеренү урыннары (ачык һәм ябык сыену урыннары, җайлаштырылган базлар, идән аслары һәм башкалар).

Гражданнар оборонасының саклану корылмаларына яраклаштырыла торган җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналары СП 88.13330.2014 СНиП II-11-77*кагыйдәләре җыентыгына туры килергә тиеш. Гражданнар оборонасының саклану корылмалары» һәм ГОСТ Р 42.4.03-2015 «Гражданнар оборонасы. Гражданнар оборонасының саклану корылмалары. Классификацияләү. Гомуми техник таләпләр».

**Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарын әзерлеккә китерү сроклары**

Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналары мобилизация чорында һәм хәрби хәрәкәт вакытында саклану корылмалары өчен яраклаштырыла, һәм аларны 12 сәгатьтән артмаган вакытта яшеренүчеләрне кабул итүгә әзерлеккә китерергә тәкъдим ителә.

**2. Яшерен урын буларак файдаланылган җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарына таләпләр**

Тирәнәйтелгән биналарның биеклеге 1,7 м дан ким булмаска тиеш. Төп биналарның идән мәйданы нормасын бер яшеренгән кешегә 0,6 кв. м. исәбеннән дип кабул итәргә кирәк. Бинаның эчке күләме бер яшеренгән кешегә 1,2 куб. м дан ким булмаска тиеш.

Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарына керү урыннарының саны икедән дә ким булмаска тиеш.

Суүткәргеч, канализация, җылыту, электр белән тәэмин итүнең транзит линияләре, шулай ук кысылган һава үткәргечләре, газ үткәргечләре һәм җылы суүткәргечләре сыену урыннары аша сүндерү җайланмалары булганда гына рөхсәт ителә.

Биналарда яшеренгән кешеләргә кирәкле булган шартларны тәэмин итү өчен гамәлдәге вентиляция, су белән тәэмин итү һәм канализация системалары максималь кулланыла. Биналарны һава белән тәэмин итү чиста вентиляция режимы буенча башкарылырга тиеш.

Эшләү дәвамлылыгы буенча яшеренү урыннары, гадәти зарарлану чаралары гамәлдә булган чорда, бер тәүлеккә кадәр саклануны тәэмин итә.

**Әзерлек эшләренә таләпләр**

**- төрле конструкцияләренең саклагыч үзлекләрен арттыруга түбәндәгечә ирешелә:**

- конструкцияләрне аларның конструктив схемаларын үзгәртмичә ныгыту;

- конструкцияләрне аларның конструктив схемаларын үзгәртеп ныгыту.

Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарын халыкның яшеренү урыннарына җайлаштырганда, ныгыту конструкциясе һәм эчке җиһазлар бу биналардан турыдан-туры билгеләнеше буенча файдалануны кыенлаштырырга яки технологик процессны реконструкцияләүгә комачауларга тиеш түгел.

**Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарын халыкка яшеренү урыны буларак җайлаштыру өчен түбәндәге эшләрне башкарырга кирәк:**

- тышкы койма конструкцияләрендә кирәкмәгән тишекләрне ябарга (шул исәптән кул астындагы материаллар белән дә);

- кешеләрнең нормаль яшәү шартларын тәэмин итәчәк гамәлдәге вентиляция, санитар-техник һәм көнкүреш җиһазларын әзерләргә;

- киртәләп торучы конструкцияләрне һәм ишекләрнең герметизациясен ныгытырга.

**Яшеренүчеләрне җыю радиусы буенча таләпләр**

Яшеренүчеләрне җыю радиусы 500 метрдан да артмаска тиеш.

**Яшерен урынны карап тоту таләпләре**

Идарәче компанияләр һәм ТСЖлар (торак милекчеләре ширкәте) яшеренү буенча җаваплы кешене билгелиләр. Яшеренү буенча җаваплы кешенең бурычына дежурларны билгеләү керә.

**Яшеренү урыннарын җиһазлау һәм алардан файдалануга таләпләр**

Идарәче компанияләр һәм ТСЖлар җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарын сыену урыны итеп җиһазлау һәм алардан файдалану өчен шартлар тудыралар.

Яшеренү урыннарында 100% яшеренүчеләрнең бер кешесенә 1 литр исәбеннән **техник су запасы** каралырга тиеш.

Яшеренү урыннарында **дымлы җыештыру өчен** швабралар, чиләкләр һәм чүпрәкләр булырга тиеш.

Яшерен урынны җиһазландыру өчен зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү өчен **санитар сумка** булдыру тәкъдим ителә.

**Капланып аста калган урыннардан чыгу буенча иң гади эшләрне башкару өчен** түбәндәге эш кораллары (2 данәдән азрак) кирәк булачагын истә тотарга кирәк: ломнар, көрәкләр, багорлар, балталар, чиләкләр, арбалар.

**Чүп җыю өчен бак урнаштыру**

Яшеренү урынында чүп җыю өчен бак булдырырга кирәк. Бакның күләме 1 кешегә кимендә 2 литр чүп-чар исәпләп билгеләнә. Бакның капкачы герметик булырга тиеш, аны мөмкин кадәр вентиляция тишегенә якынрак куярга кирәк.

**Санузеллар урнаштыру һәм җиһазлау**

ИК (ТСЖ) стационар бәдрәф оештыруны күздә тотарга тиеш, ә ул мөмкин булмаса, бинаны алдан ук яшеренүчеләргә 100% исәбеннән биобәдрәфләр белән тәэмин итәргә кирәк.

Яшеренү урыннарының күренә торган җирендә «Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарында яшеренүчеләрнең үз-үзләрен тоту кагыйдәләре», шулай ук тыю билгеләре (кушымта) урнаштырылырга тиеш.

**3. Яшеренү урыннарын һәм яшеренүчеләрнең аларга таба хәрәкәт итү маршрутларын билгеләү тәртибе**

Идарәче компанияләр һәм ТСЖ яшеренгән ышык урыннарны һәм хәрәкәт маршрутларын билгеләү өчен түбәндәге чараларны үткәрәләр.

**Яшеренү урынын билгеләү**

Яшеренү урынын билгеләү яшеренүгә керү урынында күренеп торган урында урнаштырылган билге кую юлы белән башкарыла. Билгеләү билгесе 50 х 60 см зурлыгындагы турыпочмактан гыйбарәт, аның эчендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- яшеренү урынының инвентарь номеры;

- яшеренү урыны караган оешма (идарәче компаниянең, (ТСЖ) исеме, адресы);

- ачкычларны саклау урыннары (телефоннар, адреслар, җаваплы затларның вазыйфалары һәм фамилияләре).

**Яшеренү урыннарына хәрәкәт маршрутларын билгеләү**

Яшеренү урыннарына хәрәкәт маршрутлары көндезге һәм төнге вакытта яхшы күрү мөмкинлеге булган урыннарда күрсәткечләр белән билгеләнә (төнге вакытта күрсәткечләр яктылык маскировкасы буенча таләпләрне исәпкә алып яктыртыла). Күрсәткечләр хәрәкәт маршрутының юнәлеше үзгәргәндә билгеләнә. Күрсәткечнең озынлыгы 50 см һәм киңлеге 15 см, ак төскә кара белән: ЯШЕРЕНҮ УРЫНЫ дигән язу языла һәм ул керү урынына кадәр бер метр арада булырга тиеш.

Һәрбер яшеренү урынында ким дигәндә ике ачкыч комплекты булырга тиеш. Аның бер комплекты яшеренү буенча җаваплы кешедә, икенчесе идарәче компаниядә (ТСЖ) саклана.

**4. Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналары урнашкан урын турында халыкка хәбәр итү тәртибе**

Стендларда, йорт подъездларында, идарәче компанияләр сайтында, торак милекчеләре ширкәтләрендә, муниципаль берәмлекнең укыту-консультация пунктларында яшеренү урыны буларак файдаланыла торган җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналары адреслары белән мәгълүмат урнаштырылырга тиеш.

**5. Яр Чаллы шәһәре халкына хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән һәм куркынычлардан саклану өчен җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарын файдалану буенча практик тәкъдимнәр.**

**Урамда булганда:**

**«ҺАВА ТРЕВОГАСЫ»** сигналы вакытында:

Экстрен хәбәрне урам тавыш көчәйткечләре яки башка хәбәр итү чаралары аша игътибар белән тыңлагыз.

Хәбәр, сиреналарны да кушып, күп тапкырлар, кимендә ике-өч тапкыр кабатлана.

Хакимият органнары вәкилләре, Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгы яки полиция хезмәткәрләре күрсәтмәсе буенча эш итәргә. Тынычлык һәм тәртип сакларга. Якындагы яшерен урынга барырга.

**Йорттагы фатирда булганда:**

**«ҺАВА ТРЕВОГАСЫ»** сигналы вакытында:

Урам тавыш көчәйткечләре яки башка хәбәр итү чаралары аша **хәбәр итүнең тавыш сигналы (сирена) тапшырылачак.** Өч минут дәвамында

сиренаның өзлексез яңгыравы яки сәнәгать предприятиеләре, оешмаларның өзлексез гудоклары «Барыгызга да – игътибар!» сигналын аңлата. Сезгә СМС хәбәр җибәрелергә мөмкин.

Сигналдан соң радиоретрансляция челтәрен, телевизорны кабызырга кирәк. Сез «Һава тревогасы!» сигналын ишетерсез. Җирле радио һәм телевидение аша да хәбәр тапшырылачак. Алынган мәгълүматны күршеләргә дә җиткерегез, аннары алынган мәгълүмат буенча эш итегез.

**Сез булмаганда газ шартлау мөмкинлеген бетерү өчен түбәндәгеләрне үтәү мөһим:**

Газны ябарга кирәк. Моның өчен газ вентилен борып, «ябык» хәлгә китерергә. Газ вентиле кухняда, газ исәпләү приборы янәшәсендә була.

**Янгын чыгу**

Электр утларын сүндерергә кирәк. Электр утларын сүндерү өчен автоматлар тумблерларын түбәнге хәленә китерергә кирәк. Автоматлар электр щитында фатирга керү урыны янында яисә баскыч мәйданчыгында була.

**Су басу куркынычын бетерү өчен түбәндәгеләрне үтәү мөһим:**

Кайнар һәм салкын су краннарын ябарга кирәк. Моның өчен кранны борып, «ябык» хәлгә китерергә. Кайнар һәм салкын су краннары гадәттә бәдрәф бүлмәсендә була, ләкин ванна бүлмәсендә яки прихожийда да булырга мөмкин.

**Азык-төлек продуктларын саклау өчен тиешле чаралар күрү мөһим**

Продукцияне полиэтилен капчыкларга тутырыгыз һәм идәндә торган шкафларга, өстәлләргә, тумбаларга урнаштырып куегыз.

Балаларны киендерегез. Фатирны бикләгез.

Ишектә түбәндәгеләр язылган язу калдырыгыз (аны скотч яки башка ысул белән беркетегез) :

- Сезнең бинадан чыккан көнегез һәм вакытыгыз;

- кешеләр исемлеге (фамилиясе, исеме, атасының исеме);

- Сез барасы яшеренү урыны адресы (мәсәлән, йортның подвалы);

- Сезнең белән элемтәгә керү өчен телефон номерлары.

Иң кирәкле булган әйберләр җыелмасын алыгыз.

Яшеренү урынына барганда һәм аңа кергәндә катгый тәртип сакларга кирәк:

- җыелып тормаска;

- алда баручыларны узып китмәскә.

**Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарын тутыру тәртибе**

Бинага кергәч, буш урыннарны яки бу бинада булган дежурлар күрсәткән урынны тиз һәм ыгы-зыгы килмичә генә алырга кирәк.

Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарын тутырганда тышкы ишекләр яшеренү буенча җаваплы кеше командасы буенча ябыла.

**6. Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарыннан чыгу тәртибе**

Һава тревогасының бетүе турында мәгълүмат белән «Барыгызга да - игътибар!» сигналын алганнан соң, яшеренү буенча өлкән кеше рөхсәтеннән башка, чыгу куркынычсызлыгы һәм яшеренүчеләрнең өйләренә тыныч кына кайту мөмкинлеге билгеләнгәнче, җир асты киңлегендәге һәм башка биналардан чыгарга ярамый.

**Әгәр дә яшеренү урыны янында түбәндәгеләр булу турында мәгълүмат алынса, күрсәтелгән бинадан чыгу рөхсәт ителми:**

шартламаган сугыш кирәк-яраклары;

- янгын чыгу;

җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка бүлмәләре урнашкан бинаның җимерелүе.

Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарыннан яшеренүчеләрне эвакуацияләү мондый тәртиптә башкарыла: башта җир өстенә берничә кеше чыга, алар үзләре чыга алмаганнарга ярдәм күрсәтә, аннары зыян күрүчеләр, картлар һәм балалар эвакуацияләнә, ә аннан соң – калганнар.

Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарыннан чыгару тиешле сигналдан соң яки кешеләрнең тормышына куркыныч тудырган корылманың авария хәлендә булу очрагында, яшеренү урыны буенча өлкән кеше күрсәтмәсе буенча башкарыла.

**7. Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналары урнашкан урыннар турында халыкка хәбәр җиткерү тәртибе**

Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналары урнашкан урыннар турында идарәче компанияләр стендларында, муниципаль берәмлекнең укыту-консультация пунктларында һәм аларның сайтларында, шулай ук эш урыннары буенча белергә мөмкин.

**8. Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарында яшеренгәндә, яшеренүче кеше үзе белән нәрсәләр алырга тиеш**

Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка биналарында яшеренү урыннарына барырга әзерләнгәндә, яшеренүче кеше үзе белән «Иң кирәкле әйберләр җыелмасы» алырга тиеш, ул тирәнәйтелгән яки башка биналарда бер яки ике тәүлек дәвамында куркынычсыз торуны тәэмин итәргә тиеш.

«Иң кирәкле әйберләр җыелмасы» рюкзакларда яки сумкаларда сакланырга тиеш, аларны гаилә әгъзалары арасында бүлеп, күчереп йөртү мөмкинлеге булу яхшы. «Иң кирәкле әйберләр җыелмасы» ел саен тикшерелә һәм яңартыла.

«Иң кирәкле әйберләр җыелмасы»нда шәхси саклану чаралары, төп документлар, азык-төлек, су, дарулар, алмаш кием, юрган, телефон һәм башка кайбер кирәкле әйберләр булырга тиеш.

**«Иң кирәкле әйберләр җыелмасы»ның һәм башка мөһим кирәк-яракларның авырлыгы түбәндәгечә булырга тиеш:**

- ир-атлар өчен – 30 кг;

- хатын-кызлар өчен –10 кг;

- егетләр һәм кызлар өчен:

• * 14 яшь – 12 һәм 4 кг;

• * 15 яшь – 15 һәм 5 кг;

• * 16 яшь – 20 һәм 7 кг;

• * 17 яшь – 24 һәм 8 кг.

**Шәхси саклану чаралары**

Һәрбер яшеренгән кешегә үзе белән үз-үзеңне коткару чарасы алырга тәкъдим ителә, әмма противогаз, респиратор кебек башка шәхси саклану чаралары да булырга мөмкин.

**Аптечка**

Аптечканың составы: бинтлар, лейкопластырь, йод, шулай ук сезнең гаилә әгъзалары даими эчә торган медицина препаратлары.

**Төп документлар**

Паспорт, хәрби билет, хезмәт кенәгәсе, пенсия таныклыгы, никах турында таныклык, бала туу турында таныклык, белем турында документлар, милек хокукын дәүләт теркәве турында таныклык, Дәүләт Пенсия фондының иминият таныклыгы, салым органында физик затны исәпкә алу турында таныклык, банк пластик карталары, акча һәм аеруча кыйммәтле әйберләр.

**Туклану продуктлары һәм су запасы**

Азык төлек һәм су запасларын түбәндәге срокка алырга кирәк:

- бер тәүлеккә кадәр, гадәти зарарлану чаралары гамәлдә булган чорда;

- ике тәүлеккә кадәр, әгәр яшеренү урыны радиоактив пычрану мөмкинлеге зонасында урнашкан булса.

Азык-төлек продуктларыннан суыткычсыз озак саклана торганнарын алырга кирәк. Иң яхшысы – көчле исләре булмаган һәм саклагыч пакетлардагы (пергамент кәгазьдә, целлофанда, төрле консервлар рәвешендә) ризыклар.

Түбәндәге җыелма тәкъдим ителә:

- өлкән кеше өчен сохари, печенье, кәгазь яки целлофан пакетлы галетлар, кулланырга әзер ит яки балык консервалары, консерв пычагы һәм югары калорияле продуктлар (шоколад, печенье), чәй, конфет, шикәр-рафинад, тоз һәм башкалар;

- балалар өчен, аларның яшен һәм сәламәтлек торышын исәпкә алып, махсус балалар ризыгы (яшь буенча), куертылган сөт, коры сөт, җиләк-җимеш эчемлекләре һәм башкалар.

Һәр кешегә тәүлегенә ким дигәндә 4,5 литр су алырга кирәк. Кечкенә балаларга һәм йөкле хатын-кызларга күбрәк су кирәк.

Эсседә су ихтыяҗы ике тапкыр арта. Су пластик яки эмаль савытта сакланырга тиеш. Пыяла савыт кулланмау яхшы, чөнки ул ватылырга мөмкин. Әгәр дә сез шешә суын сакласагыз, аны ярты ел саен алмаштырыгыз.

**Савыт-саба**

Савыт-саба: тәлинкә (миски), чынаяк (кружка), кашык – күп тапкыр куллана торган, бер тапкыр куллана торганны да алырга мөмкин.

**Башка мөһим кирәк-яраклар**

Үзең белән фонарь (иң яхшысы диодлы), батареялы радиоалгыч, запас батареялар, сыбызгы, коры ягулык, блокнот, каләм алу яхшы.

Үзегез өчен берничә китап һәм балалар өчен уеннар алыгыз.

Җир асты киңлегенең тирәнәйтелгән һәм башка бүлмәләрендә уңайлы булсын өчен үзең белән утыру өчен җайланма (урындык, табуретка яки эскәмия) алырга кирәк, аның утыру мәйданы мәсәлән, 50-60 см дан артык түгел. Дымлы дезинфекция салфеткалары, шулай ук чүп пакетлары һәм бәдрәф кәгазе кебек санитария кирәк-яракларын алырга онытмагыз.

**Җир асты киңлеге тирәнлекләрендә һәм башка биналарында яшеренгәндә үзең белән нәрсәләр алырга ярамый**

**Үзең белән алырга ярамый:**

- спиртлы һәм спирты булган эчемлекләр;

- тәмәке эшләнмәләре;

- шартлау куркынычы булган һәм тиз кабынып китүче матдәләр;

- көчле исле матдәләр;

йорт хайваннары, бүлмә үсемлекләре;

- зур әйберләр.